ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 11 » 04 2019ел №322

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалының үсешен стимуллаштыру максатларында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына кушымта итеп бирелгән башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Җитәкче С. П. Самонина

А. В. Сучкова
2-80-12

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланды «__» _______20____ №____

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, муниципаль берәмлекләр) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Ютазы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасында һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына узган кварталдан соң килә торган айның 30 числосына кадәр, тиешле финанс елында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турындагы карарда күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә тиешле финанс елына һәм план чорына бирелә.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын төп бүлүче - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Финанс – бюджет палатасы (алга таба - Финанс-бюджет палатасы).

5. Башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

6. Тиешле квартал өчен I-муниципаль берәмлеге өчен башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Mt_i^{кв} = НПД_i^{год} – НПД_i^{пт},$$

биредә:

$МТ_i^{кв}$- тиешле квартал өчен i муниципаль берәмлегенә башка бюджетара трансферт күләме, сум;

$НПД_i^{год}$ -Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы территориясендә теркәлгән салым түләүчеләрдән Татарстан Республикасы бюджетына ел башыннан арта бару нәтиҗәсе белән һөнәри керемгә салым суммасы;

$НПД_i^{пт}$-Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә теркәлгән салым түләүчеләрдән кергән моңа кадәр башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында исәпкә алынган.һөнәри керемгә салым суммасы.

7. Муниципаль район составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шарты булып җирлекнең башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарның юнәлешләрен билгели торган норматив хокукый акты булу тора.

8. Башка бюджетара трансфертлар Финанс-бюджет палатасы тарафыннан җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачык булган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары счетларына шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә.

9. Җирлекләрнең башкарма комитетлары  Финанс-бюджет палатасына финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыралар.

10. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына әлеге Тәртип нигезендә файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Финанс-бюджет палатасының финанс хисап елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә, күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларның калдыгыннан артмаган күләмдә акчалар агымдагы финанс елында шәһәр һәм авыл җирлеге бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин.

Әгәр әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның кулланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

11. Җирлекләр башкарма комитетлары һәм вазыйфаи затлар, закон нигезендә, тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү өчен җаваплы.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

13. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны Финанс-бюджет палатасы башкара.